**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының**
**Акбаш авыл җирлеге составына керә торган Акбаш тимер юл станциясе торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар**

2019 елның 16 ноябре № 1
15:00 сәгать.,
Акбаш тимер юл станциясе., МФЦ

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 16 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән «Бөгелмә муниципаль районының Акбаш авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән , 1 группа инвалидларыннан, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 2020 елда үзара салым кертү буенча 250 сум салым алу һәм шул җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

- Акбаш тимер юл станциясе торак пунктында салкын су белән тәэмин итү челтәрен төзәтү өчен.

«ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 390 граждан кертелгән, җыенда катнашучылар саны 203 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 203 кеше тавыш бирде;

җыенда катнашучы 0 кеше «юк» позициясе өчен тавыш бирде;

гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше канәгать калды.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге составына керә торган Акбаш тимер юл станциясе торак пунктында уздырылган гражданнар җыенын - дөрес дип танырга.

2. Бөгелмә муниципаль районының Акбаш авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән , 1 группа инвалидларыннан, тыл хезмәтчелләреннән тыш, 2020 елда үзара салым кертү буенча 250 сум салым алу һәм шул җыенган акчаларны җирле мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

- Акбаш тимер юл станциясе торак пунктында салкын су белән тәэмин итү челтәрен төзәтү өчен.» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында (http://bugulma.tatar.ru, Авыл җирлекләре бүлегенең «Акбаш авыл җирлеге» бүлекчәсендә Акбаш тимер юл станциясе торак пунктының.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче,**
**Акбаш авыл җирлеге башлыгы** ____________________ **Р.Т.Хуҗиев**